**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 июнь № 374

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы; 2015 ел, 21 сентябрь, 693 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 830 нчы; 2016 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2016 ел, 3 ноябрь, 812 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсын үткәрү буенча республика конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан И.Ю.Просвирякованы чыгарырга;

комиссия составына Юлия Ивановна Абдрееваны – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасарын кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2015 ел, 29 гыйнвар, 47 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2016 ел, 10 август, 551 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1072 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан И.Ю.Просвирякованы чыгарырга;

комиссия составына Юлия Ивановна Абдрееваны – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасарын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\374.doc